| | |
|---|---|
| **ГЛАВА ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 6 11.11.2024 ел

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 21 ноябре 12.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының беренче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 21 ноябре 14.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының икенче этабын билгеләргә.
3. 2024 елның 21 ноябре 16.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының өченче этабын билгеләргә.

4. 2024 елның 21 ноябре 16.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында " мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының дүртенче этабын билгеләргә.

Гражданнар җыенының барлык этапларын уздыру урыны итеп Турай авылы, Үзәк урам, 11А й. адресы буенча урнашкан Турай авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Турай авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Кама ур., 104 й., Яңа ур., 1-3 й., Яшьләр ур., 8,10,21 й., Окольная ур, 1-37 й.

Икенче этап: Овражная ур., 1-37 й., Совет ур.,1-33 й.

Өченче этап: Үзәк ур., 1-44 й. Крайняя ур., 1-33 й.

Дүртенче этап: Мир ур., 1-18 й. Мәктәп ур.,1-12 й.

2. «2025 елда үзара салым акчаларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( Турай торак пунктындагы яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү өчен материал сатып алу, зонаны киртәләү)

2) торак пункт территориясен төзекләндерү ( Турай торак пунктында үлән чабу өчен триммер сатып алу, Турай торак пунктында үлән чабу хезмәтләре күрсәтү; трактор өчен чапкыч сатып алу. )

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Турай торак пунктында кышкы чорда юлларны кардан чистарту ( шартнамә буенча эшләр өчен түләү); Окольная , Совет урамнары һәм тыкрыклар буйлап чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу. )

4 ) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (1 ( бер ) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пунктының Крайняя урамында 1(бер) данә янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру.)

5) һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( Турай авылында махсус хәрби операциядә һәм Әфганстанда катнашучыларга һәйкәлләр кую)

3. «РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Турай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Турай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы ________________ Г.Б.Куляшова
(имза) (имзаның аңлатмасы)